# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлегенең Өргәнче авылында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

2024 елның «28» октябреннән № 8

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлегенең Өргәнче авылындагы гражданнар җыены нигезендә

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Өргәнче авылы Зирекле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш; Россия Федерациясе Кораллы көчләренең контракт буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләре, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзалары; 85 яшьтән өлкәнрәк гражданнар һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалар юлламасыннан тыш, 2025 елда үзара салымны 600 сум күләмендә кертергә.

2. Түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (җәй көне территорияне чүп үләннәрдән чабу, ягулык-майлау материаллары, трактор чапкычына һәм бензотриммерларга запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).».

3. Әлеге карарны Өргәнче Зирекле авыл җирлеге мәгълүмат стендында урнаштыру, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Яңа Чишмә муниципаль районы рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгару юлы белән: https://novosheshminsk.tatarstan.ru, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә 10 көн эчендә бастырып чыгарырга:https://pravo.tatarstan.ru.

Халык җыенында рәислек итүче,
Яңа Чишмә муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге башлыгы

Ж.Г. Гайфетдинов